ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

---

**Постановление** **Карар**

**№ 6** **11 ноябрь 2022 ел**

2023 елда Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенең Алабакүл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14.81 маддәсе нигезендә, Ютазы мунипипаль районы "Димтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1. 2022 елның 24 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлегенә керүче Алабакүл торак пунктында 2023 елда Алабакүл торак пунктының Үзәк урамы, 8а санлы торак йорт янында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җыен билгеләргә.

2. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Балачак инвалидларыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, Ютазы муниципаль районының Алабакүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 200 (Ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- Алабакүл авылының Үзәк урамы, Җәлил урамы буенча юлларны асфальтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

"Димтамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов